**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"22" ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Территорияне төзекләндерү һәм чистарту:

- Яңа Шимбер авылы территориясен чистарту, агач һәм куаклар кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү (яктырткычлар, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алыштыру) һәм яктырткычлар сатып алу.

2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Яңа Шимбер авылында гадәттән тыш хәлләр вакытында су белән тәэмин итү системасының өзлексез эшләве өчен генератор урнаштыру өчен төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;
- янгын гидранты өчен колонка сатып алу;
- су алу урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү)

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.